ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.11.2020 Казан шәһәре № 127

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2018 елның 11 июлендәге 70 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертү буенча конкурслар уздыруның бердәм методикасына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 24 сентябрендәге 1546 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмә раслау турында» 2018 елның 11 июлендәге 70 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2020 елның 29 апрелендәге 52 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2.9 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Конкурс комиссиясе тарафыннан утырышны аның әгъзасы яки кандидаты тәкъдиме белән, мондый карар сәбәбен (нигезен) күрсәтеп, видеоконференция форматында (техник мөмкинлек булган очракта) уздыру турында конкурс комиссиясе карары кабул ителергә мөмкин.»;

4.12 пунктта «бәяли» сүзеннән алда «һөнәри дәрәҗәсен» сүзләрен өстәргә;

4.12.1 пунктта ундүртенче абзацта «10 балл» сүзләреннән соң «, минималь балл – 0 балл» сүзләрен өстәргә;

4.12.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Тест уздыру нәтиҗәләрен бәяләгәндә максималь балл – 5 балл, минималь балл – 0 балл.»;

4.12.3 пунктта сигезенче абзацта «10 балл» сүзләреннән соң «, минималь балл – 1 балл» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 4.12.4 пунктын өстәргә:

«4.12.4. Дәүләт комитеты тарафыннан конкурс комиссиясе эшчәнлеге, шулай ук кандидатлар тарафыннан конкурс процедураларын узу өчен тиешле оештыру һәм матди-техник шартлар тудырыла.»;

4.13 пунктның икенче абзацында «аларның ахыргы балларын кимету тәртибендә» сүзләрен өстәргә.

Рәис С.Е. Иванов.